Беренче сыйныф укучылары белән очрашу Кадошкино районы vзәк китапханәсе хезмәткәрләре очен кvркәм традициягә әверелгән.
Балаларда уку, китапны ярату кvнекмәләре булдыру максаты белән, китапханә хезмәткәре Данара Идрис кызы Альмяшева аларны китап белән эш итv кагыйдәләре, китапханәдән файдалану кагыйдәләре, китапханәдә vзенне ничек тотарга кирәклеге белән таныштырган.   Укучылар һәр китапнын vз адресы барлыгын белгәннәр. Беренче сыйныф укучылары торле балалар журналларын һәм китапларын зур кызыксыну белән караганнар.
- Без ел саен шундый чаралар vткәреп киләбез. Укучылар район китапханәсе белән танышып кына калмыйлар, аларнын китапханә яраткан урыннарынын берсенә әверелә. Һәм без китап яратып укучылар тәрбиялибез: бvген укырга яратмаган яшьләр саны азая, - ди Динара Идрис кызы Альмяшева.
Яшь кунаклар яна белем алу һәм кvнелле ял итv очен әти-әниләре белән китапханәгә йорергә планлаштыралар.